**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 9 июнь № 385

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне һәм дини йә милли нигездәге каршылыкларны алдан кисәтүне мониторинглауның комплекслы системасында катнашучыларның мәгълүмати багланышлары регламентын раслау турында» 2015 ел, 25 ноябрь, 892 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне һәм дини йә милли нигездәге каршылыкларны алдан кисәтүне мониторинглауның комплекслы системасында катнашучыларның мәгълүмати багланышлары регламентына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне һәм дини йә милли нигездәге каршылыкларны алдан кисәтүне мониторинглауның комплекслы системасы турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Президентының 2016 ел, 27 февраль, ПУ-215 нче Указын үтәү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне һәм дини йә милли нигездәге каршылыкларны алдан кисәтүне мониторинглауның комплекслы системасында катнашучыларның мәгълүмати багланышлары регламентын раслау турында» 2015 ел, 25 ноябрь, 892 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне һәм дини йә милли нигездәге каршылыкларны алдан кисәтүне мониторинглауның комплекслы

системасында катнашучыларның мәгълүмати багланышлары регламентына (алга таба – Регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Регламентның 1.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Комплекслы системасының мәгълүмати багланышларында катнашучылар түбәндәгеләр:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты;

Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты (килешү буенча);

Татарстан Республикасы Президентының Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү идарәсе (килешү буенча);

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын теркәү идарәсе;

Татарстан Республикасы прокуратурасы (килешү буенча);

Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсе (килешү буенча);

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча);

Федераль миграция хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча);

Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча);

Федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы (килешү буенча);

Республика «Татмедиа» басма һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы;

Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы;

Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы;

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы;

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы;

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы;

Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары (килешү буенча);

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе (килешү буенча);

гражданнар җәмгыяте институтлары: иҗтимагый берләшмәләр, иҗтимагый һәм дини берләшмәләр, эксперт җәмгыятьләре вәкилләре, массакүләм мәгълүмат чаралары (килешү буенча).»;

әлеге Регламентка түбәндәге эчтәлекле $5^1$ пункт өстәргә:

| «$5^1$. Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсе (килешү буенча) | | | |
|---|---|---|---|
| $5.1^1$. | Җинаять эшләрен тикшергәндә билгеле булган җинаять кылуга этәргән шартлар | һәр ярты ел саен 20 | б) милләтара һәм конфес- |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | яки башка закон бозулар, шулардан:<br>милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр һәм экстремизмга каршы тору өлкәсендә;<br>террорчылыккка каршы тору өлкәсендә | июльдә һәм 20 гыйнвар-да | сияара мөнәсә-бәтләр өлкә-сендә билгеле булган хокук бозулар, шулай ук аларны кылу сәбәпләре һәм шартлары ту-рында хокук саклау орган-нары мәгълү-маты». |
| $5.2^{1}$. | Билгеле булган бозулар нәтиҗәләре буенча эш итү чаралары, шулардан:<br>милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр һәм экстремизмга каршы тору өлкәсендә;<br>террорчылыккка каршы тору өлкәсендә | | |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков